| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРЫНДЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30» гыйнвар , 2024 ел Борындык ав. № 1

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталарга туры китереп, 8370,20 сум күләмендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://burunduk-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р.Гайнетдинов

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 е. «30» гыйнварындагы
1номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Борындык авыл жирлеге»
муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3591,03 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 961,36 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3817,81 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Борындык авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 е. «30» гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 451,45 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3139,58 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 961,36 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3817,81 |
| Барлыгы | 8370,20 |